**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 18 июленнән № 58-443

2025 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген оештыру, аларга ярдәм итү формалары һәм ысуллары һәм 2026 елга бурычлар

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.Л.Еронтьев 2025 елда Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген оештыру, аларга ярдәм итү формалары һәм ысуллары һәм 2026 елга бурычлар мәсьәләсе буенча мәгълүматын тыңлаганнан соң, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2025 елда Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлеген оештыру, аларга ярдәм итү формалары һәм ысуллары һәм 2026 елга бурычлар турында мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетына:
социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар челтәрен киңәйтүне һәм районның социаль проблемаларын хәл итүдә аларның ролен арттыруны тәэмин итәргә;

җирле үзидарә органнары һәм социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар арасында үзара хезмәттәшлекне тәэмин итәргә;

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар вәкилләре өчен укыту чараларын һәм семинарлар уздыруны тәэмин итәргә;

муниципаль берәмлек халкына социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тәкъдим итә торган социаль хезмәтләр өлкәсен үстерү өчен шартлар тудырырга;

3. Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә эшчәнлек алып баручы иҗтимагый берләшмәләргә тәкъдим итәргә:

региональ һәм федераль ярдәм программаларында социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмаларның катнашуын активлаштырырга;

хезмәт күрсәтүләрне үстерүгә юнәлдерелгән проектларны гамәлгә ашыруга грантлар алу хокукына конкурсларда социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар катнашуын активлаштырырга;

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген арттырырга;

социаль юнәлешле коммерциячел булмаган оешмалар эшчәнлегендә ачыклыкны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында https://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының социаль, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә муниципаль районы
Башлыгы урынбасары Н.И. Попкова